КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1013

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 587 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибендә:

13 нче пунктның 1 нче пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуга багышланган чаралар үткәрү;»;

Социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Л.О.Сулиманы чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Шәрәпов Азат Рәфыйк улын кертергә;

Алмаз Минвазыйх улы Минголов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының спорт министры урынбасары»;

Алсу Шакирҗан кызы Сәетова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министры ярдәмчесе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин